ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Постановление

“05” сентябрь, 2017 ел . | № 6

Сайлаучылар белән депутатлар очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган махсус урыннарныбилгеләү, биналар исемлеген раслау һәм аларны бирү тәртибе

«Җәмәгать чаралары турында законнарны камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 07.06.2017 ел, № 107 ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән, карар бирәм:

1. Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар исемлеген 1 нче кушымтага ярашлы билгеләргә.

2. Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Житәкче: В.В.Шрыков

Шәдче авыл җирлеге
Башкарма комитетының
05.03.2017 елның 6 санлы карарына
1 нче кушымта

Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар исемлеге

| № п/п | Биналар исемлеге (махсус билгеләнгән урыннар) | Бина урнашкан урынның адресы (махсус билгеләнгән урыннар) | Контакт мәгълүматлары |
|---|---|---|---|
| 1. | Шәдче авылы мәдәният йорты һәм бина алдындагы территория | ТР, Мамадыш районы, Шәдче авылы, Яшьләр урамы, 18 нче йорт | телефон –(8(85563) 2-52-24<br>e-mail- _________ |
| 2. | Юкәче авылы мәдәният йорты һәм бина алдындагы территория | ТР, Мамадыш районы, Юкәче авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт | телефон –(8(85563) 2-52-24<br>e-mail- __________ |
| 3. | Ямаш авылы мәдәният йорты һәм бина алдындагы территория | ТР, Мамадыш районы, Ямаш авылы, Үзәк урам, 22 нче йорт | телефон –(8(85563) 2-52-24<br>e-mail- __________ |
| 4. | Яңа Мочалкино авылы клубы һәм бина алдындагы территория | ТР, Мамадыш районы, Яңа Мочалкино авылы, Октябрь урамы, 25 нчы йорт | телефон –(8(85563) 2-52-24<br>e-mail- __________ |
| 5. | Иске Мочалкино авылы клубы һәм бина алдындагы территория | ТР, Мамадыш районы, Иске Мочалкино авылы, Овражная урамы, 27 нчы йорт | телефон –(8(85563) 2-52-24<br>e-mail- __________ |
| 6. | Вахит авылы клубы һәм бина алдындагы территория | ТР, Мамадыш районы, Вахит авылы, Татарстан урамы, 50 нче йорт | телефон –(8(85563) 2-52-24<br>e-mail- __________ |

Шәдче авыл җирлеге
Башкарма комитетының
05.03.2017 елның 6 санлы карарына
2 нче кушымта

Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе

1. Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе (алга таба – тәртип) төрле дәрәҗәдәге депутатларның сайлаучылар белән очрашулары формасында ачык чаралар үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар бирү шартларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсе 5.3 өлешенә ярашлы билгели.

2. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды эчендәге территорияләрдә, аларны үткәрү тормыш тәэмин итү, транспорт яки социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшчәнлеген бозмаса, җәяүлеләр һәм (яки) транспорт чаралары хәрәкәтенә комачаулау тудырмаса яки гражданнарның торак биналарга яки транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә комачауламаса, үткәрелә.

Бина, сайлаучылар белән эшләү һәм сайлау округында депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан тыш, башка максатларда кулланыла алмый. Бина элемтә чаралары, кирәкле җиһазлар һәм оргтехника белән җиһазландырылырга тиеш.

3. Депутатларның сайлаучылар белән очрашулары өчен биналар әлеге Тәртипкә кушымта формасы буенча депутатның язма мөрәҗәгате (гаризасы) нигезендә түләүсез файдалануга бирелә.

4. Биналар депутатның язма мөрәҗәгате (гаризасы) буенча, бина хуҗасы (учреждение җитәкчесе) белән килештерү өчен, бу көнне (вакытта) элек планлаштырылган мәдәни-массакүләм чаралар үткәрү яки бу көнне (вакытта) башка депутатлар белән алдан планлаштырылган очрашулар үткәрү сәбәпле, бина бирү мөмкин булмау ситуациясен булдырмау максатыннан бирелә. Гаризада депутатка килешү турында яки килешүдән баш тарту турында хәбәр итү ысулы (ысуллары) күрсәтелә, баш тарту сәбәпләре күрсәтелә һәм очрашуны үткәрү өчен башка көннәр һәм (яки) вакыт тәкъдим ителә. Килешүдән баш тарткан очракта депутат яңа гариза бирә. Депутатның язма мөрәҗәгате (гаризасы) очрашу уздырылганга кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча җибәрелергә тиеш (эш көннәрендә 9.00 дән 17.00 гә кадәр).

5.Депутатның язма мөрәҗәгате (гаризасы) учреждениедә билгеләнгән керүче документларны теркәүнең гомуми тәртибендә теркәлә.

6. Депутатның язма мөрәҗәгатен (гаризасын) депутат (аның вәкиле) үзе яки бина биргән учреждениенең электрон почтасы аша тапшырырга мөмкин.

7. Планлаштырылган чаралар, шул исәптән депутатларның сайлаучылар белән очрашулары турында мәгълүмат учреждение бинасында, шулай ук бинаны тәкъдим итүче учреждение сайтында, килешү көненнән 1 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

8. Депутатның сайлаучылар белән ачык чара формасындагы очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр һәм пикетлар турындагы законнарына ярашлы рәвештә үткәрелә.

Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибенә кушымта

Үрнәк формасы

______________________________

______________________________

милекченең, бина хуҗасының исеме

______________________________

(депутатның Ф.И.ә.и.)

Депутатның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен
бина бирү турында гариза

5.3 пунктына ярашлы. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы 5.3 пунктына нигшезләнеп түбәндәге адрес буенча бина бирүне сорыйм:_______________________________________________

__________________________________________________________________________

(очрашулар үткәрү урыны)

җыен формасында ачык чара үткәрү, сайлаучылар белән очрашу 20__ елның «__» _____ ______________________ планлаштырыла,

(очрашу башлану вакыты)

дәвамлылыгы _______________________________________________________.

(очрашу дәвамлылыгы)

Катнашучыларның якынча саны: ______________________________________________.

Чараны (очрашуны)үткәрү өчен җаваплы___________________________,

(Ф.И.ә.и., статус)

Контакт телефон __________________________________________________________.

Гариза бирү датасы: ___________________________

**Депутат** ______________ ____________________

(имза)

«____»_________20__ ел.